**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН** | **ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**

**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ ТЮЛЯЧИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА**

**ТЕЛӘЧЕ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** | **КАРАР**

«24» февраля 2020 с. Тюлячи № 83

Район Башкарма комитетының 2019 елның 19 декабрендәге 646 номерлы «Теләче муниципаль районында 2020 елга мәктәпкәчә мәгариф оешмалары эшчәнлеген финанслау нормативларын раслау турында» карарына үзгәрешләр кертү хакында

«Россия Федерациясендә мәгариф турында» 2012 елның 29 декабрендәге 273 номерлы Федераль законның 99 статьясы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 15 статьясындагы 1 өлешенең 11 пункты, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Муниципаль мәктәпкәчә мәгариф оешмалары эшчәнлеген норматив финанслау турында» 2019 елның 02 июлендәге 546 номерлы карары нигезендә, Теләче муниципаль районы Башкарма комитеты,

КАРАР БИРӘ:

1. Район Башкарма комитетының 2019 елның 19 декабрендәге 646 номерлы «Теләче муниципаль районында 2020 елга мәктәпкәчә мәгариф оешмалары эшчәнлеген финанслау нормативларын раслау турында» карарының 1 пунктына түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«- Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районының 2020 елга мәктәпкәчә мәгариф оешмаларында балаларны караган һәм тәрбияләгән өчен ата-аналар түләвенә ташламалар кертелгән затлар исемлеге, 3 номерлы кушымта нигезендә.».

«Теләче муниципаль районы
Башкарма комитетының
2020 елның 19 ноябрендәге
646 номерлы карарына
3 номерлы кушымта

Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районының 2020 елга мәктәпкәчә мәгариф оешмаларында балаларны караган һәм тәрбияләгән өчен ата-аналар түләвенә ташламалар кертелгән затлар исемлеге

Теләче муниципаль районының мәктәпкәчә белем бирү учреждениеләрендә балаларны карау һәм тәрбияләү өчен ата-аналар түләве алынмый:

- инвалид балаларны, ятим балаларны һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балаларны, шулай ук туберкулез интоксикациясе булган мәктәп мәгариф учреждениеләрендәге балаларны караган һәм тәрбияләгән өчен;

- өч һәм аннан да күбрәк балигъ булмаган балалары булган ата-аналардан ата-ана түләвен мәктәпкәчә белем бирү учреждениеләрендә баланы караган һәм тәрбияләгән өчен түләүне 50 процентка киметергә;

- ата-аналарның берсе 1 группа инвалид булган, мәктәпкәчә белем бирү учреждениесенә йөрүче ике бала тәрбияли торган гаиләләрдән;

- ата-аналарның берсе 1 группа инвалид булган, мәктәпкәчә белем бирү учреждениесенә йөрүче бер баланы тәрбияли торган, һәм җан башына уртача керем яшәү минимумыннан түбән булган гаиләләрдән.

Муниципаль мәгариф учреждениеләрендә балаларны караган һәм тәрбияләгән өчен түләү ташламасы ата-аналарның (законлы вәкилләрнең) гаризасы һәм гаиләнең ташламага хокукы булуын раслаучы документлар нигезендә бирелә.

Гаиләнең берничә ташламага хокукы булса, куллануга, ата-аналарның (законлы вәкилләрне) сайлавы буенча, бер ташлама гына бирелергә тиеш.».

2. Әлеге карар гамәлдәге законнар нигезендә үз көченә керә һәм 2020 елның 1 гыйнварыннан барлыкка килә торган хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны район Башкарма комитеты Җитәкчесенең социаль мәсьәләләр буенча урынбасары Д.С. Гыйниятуллинга йөкләргә.

Җитәкче Н.Н. Хаҗипов